**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«16» 12 2024 Яр Чаллы шәһәре № 5869

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының җылылык белән тәэмин итү системасы торышына мониторинг системасы турында нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, оператив мәгълүмат алу һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларының һәм системаларының ышанычлылыгын тикшереп тору максатында, Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2013 елның 12 мартындагы «Җылыту чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләрен раслау турында» 103 номерлы боергын үтәү йөзеннән, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының җылылык белән тәэмин итү системасы торышына мониторинг системасы турында нигезләмәне расларга (1 кушымта).
2. Җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга җылыту сезоны узган чорда Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының җылылык белән тәэмин итү системасы торышына мониторинг системасы турында нигезләмәгә таянырга киңәш итәргә.
3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазифаларын башкаручы А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның «16» 12.2024 5869 номерлы карарына 1 кушымта

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының җылылык белән тәэмин итү системасы торышына мониторинг системасы турында нигезләмә**

Әлеге нигезләмә «Җылылык белән тәэмин итү турында» 27.07.2010 ел № 190-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясендә җылылык белән тәэмин итүне оештыру турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 08.08.2012 ел № 808 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының җылылык белән тәэмин итү системасы торышына мониторинг үткәрү тәртибен билгели.

**1. Гомуми нигезләмәләр**

Җылылык белән тәэмин итүгә мониторинг системасын булдыруның һәм эшләвенең максаты булып. җылылык белән тәэмин итү системаларының ышанычлылыгын һәм куркынычсызлыгын арттыру, авария хәлләрен кисәтү, булдырмау, ачыклау һәм бетерү чараларын гамәлгә ашыру юлы белән, авария-торгызу эшләрен башкаруга чыгымнарны киметү тора.

Нигезләмә җылылык белән тәэмин итү системасына мониторинг системасын төзегәндә һәм эшләгәндә җирле үзидарә органнарының, җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның һәм җылылык энергиясен кулланучыларның үзара хезмәттәшлеген билгели.

Әлеге нигезләмә торак-коммуналь хезмәтләрне башкаручылар һәм кулланучылар өчен мәҗбүри.

**2. Төп төшенчәләр**

Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла: җылылык белән тәэмин итү системасының торышына мониторинг – җылылык челтәрләренең һәм җылылык белән тәэмин итү объектларының торышын күзәтү, бәяләү һәм фаразлауның комплекслы системасы (алга таба – мониторинг);

кулланучы – коммуналь хезмәтләрдән эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле булмаган, шәхси, гаилә, өй һәм башка ихтыяҗлар өчен файдаланучы граждан;

идарәче оешма – күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсе нигезендә күпфатирлы йорт белән идарә итүче оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә юридик зат, шулай ук шәхси эшмәмәкәр;

коммуналь хезмәтләр – салкын су белән тәэмин итү, кайнар су белән тәэмин итү, су бүлү, электр белән тәэмин итү һәм җылыту буенча хезмәтләр күрсәтү буенча башкаручының гражданнарга торак урыннарда уңайлы яшәү шартларын тәэмин итә торган эшчәнлеге;

ресурслар белән тәэмин итүче оешма – коммуналь ресурсларны сатуны гамәлгә ашыручы оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә юридик зат, шулай ук шәхси эшмәкәр;

коммуналь ресурслар – коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган кайнар су, салкын су, җылылык энергиясе, электр энергиясе;

җылылык белән тәэмин итү системасы – шәһәрнең (районның), торак пунктның гомуми җитештерү процессы белән берләштерелгән, торак-коммуналь хуҗалыкның билгеләнгән тәртиптә тиешле махсус рөхсәтләр (лицензияләр) алган җылылык белән тәэмин итү оешмасы тарафыннан файдаланыла торган җылылык чыганаклары һәм (яисә) җылылык челтәрләре җыелмасы;

җылылык челтәре – җылылык энергиясен кулланучыларга тапшыру һәм бүлү өчен билгеләнгән җайланмалар җыелмасы;

җылылык пункты – сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләренең, торак һәм иҗтимагый биналарның җылылык, вентиляция, һаваны кондиционерлау, кайнар су белән тәэмин итү системаларын һәм җылылыктан файдалану технологик җайланмаларын җылылык челтәрләренә тоташтыру өчен билгеләнгән җайланмалар җыелмасы (шәхси – бер бинаны яки аның өлешен җылылык куллану системаларын тоташтыру өчен; үзәкләштерелгән – ике бина яисә аннан күбрәкне шулай ук);

техник хезмәт күрсәтү – эшләнмәнең (җайланманың), аны билгеләнеше буенча файдаланганда, саклаганда яки транспортировкалаганда, эшкә сәләтлелеген яки төзеклеген саклау буенча операцияләр комплексы яки операция;

агымдагы ремонт – объектның техник һәм икътисадый характеристикаларын билгеләнгән чикләрдә тоту өчен, тиз туза торган аерым состав өлешләрен һәм детальләрен алыштырып һәм (яки) торгызып башкарыла торган ремонт;

капиталь ремонт – объектның техник һәм икътисадый характеристикаларын проект күрсәткечләренә якын булган күрсәткечләргә кадәр торгызу өчен, теләсә нинди состав өлешләрен алыштырып яки торгызып башкарыла торган ремонт;

технологик бозылулар – нәтиҗәләрнең характерына һәм авырлыгына бәйле рәвештә җылылык белән тәэмин итү системасы эшендә һәм эксплуатацияләүче оешмалар эшендә бозылулар (персоналга йогынты; энергия чыганагы параметрларыннан тайпылу; экологик йогынты; җиһазларга зыян килү күләме; ышанычлылык кимүнең башка факторлары), инцидентка һәм авариягә бүленә;

инцидент – җиһазларның һәм (яки) челтәрләрнең эшләми башлавы яки зыян килү, билгеләнгән режимнардан тайпылу, җитештерү объектында эшләр алып бару кагыйдәләрен билгели торган федераль законнарны, норматив - хокукый актларны һәм техник документларны бозу, шул исәптән:

- технологик эшләми башлау – җиһазны җылылык энергиясен җитештерү һәм (яки) кулланучыларга тапшыру процессын бозуга китергән мәҗбүри туктату яки эшкә сәләтен чикләү, әгәр алар авария билгеләрен үз эченә алмаса;

- функциональ эшләми башлау – җиһазларның җылылык энергиясен җитештерү һәм (яки) тапшыруның технологик процессына йогынты ясамаган (шул исәптән резерв һәм ярдәмче җиһазларның) төзексезлеге, шулай ук саклау һәм автоматиканың

дөрес эшләмәве, персоналның хаталы гамәлләре, әгәр алар кулланучыларны чикләүгә һәм җибәрелә торган энергиянең сыйфатын киметүгә китермәгән очракта;

җылылык белән тәэмин итү объектларында авария – җылылык белән тәэмин итү системалары элементларының, челтәрләренең һәм чыганакларының кулланучыларга һәм абонентларга җылылык энергиясен 12 сәгатьтән артык булмаган вакытка һәм кайнар су белән тәэмин итүне 36 сәгатьтән артык вакытка туктатуга китергән эшләми башлавы;

төзексезлек – җылылык белән тәэмин итү системасы эшендә технологик процесс белән билгеләгән таләпләрнең берсе булса да үтәлми торган башка бозылулар.

## 3. Мониторингның төп бурычлары

3.1. Җылылык белән тәэмин итү системасы торышына мониторингның төп бурычлары булып тора:

- җылылык белән тәэмин итү объектларының торышы турында, җылылык белән тәэмин итү системаларында барлык килә торган аварияләр һәм төзексезлекләр турында һәм аларда башкарыла торган ремонт эшләре турында статистик белешмәләр җыю, эшкәртү һәм анализлау;
- җылылык челтәрләрендә ремонт эшләрен башкару планнарын төзү процессын оптимальләштерү;
- җылылык челтәрләрен карап тоту һәм ремонтлау эшләрен башкару өчен, финанс чаралары бүлеп бирүне нәтиҗәле планлаштыру.

3.2. Мониторинг системасы үз эченә ала:

- мәгълүмат җыю;
- мәгълүматны саклау, эшкәртү һәм тапшыру;
- карар кабул итү өчен мәгълүматны анализлау һәм бирү.

3.2.1. Мәгълүмат җыю.

Җылылык челтәрләре торышына мониторинг мәгълүматларын җыю системасы муниципаль берәмлек территориясендә җылылык челтәрләрен күзәтүнең гамәлдәге барлык ысулларын берләштерә.

Мәгълүмат җыю системасына башкарылган ремонт буенча белешмәләр һәм эксплуатация персоналы туплый торган белешмәләр кертелә.

Түбәндәге мәгълүмат җыела:

- җылылык челтәрләре салуның технологик җайланмалары белешмәләре базасы;
- башкарма документлар;
- җылылык белән тәэмин итү объектларында үткәрелгән ремонт турында белешмәләр;
- төзелеп беткән, киңәйтелгән, реконструкцияләнгән, техник яктан яңадан җиһазландырылган җылылык белән тәэмин итү объектларын файдалануга тапшыру турында белешмәләр;
- җылылык белән тәэмин итү объектларында барлыкка килә торган авария хәлләрен исәпкә алу реестры, объектның исемен, объектның адресын, авария хәле барлыкка килүгә китергән сәбәпләрне, авария хәлен бетерү буенча күрелгән

чараларны күрсәтеп, шулай ук кулланучыларны җылылык белән тәэмин итүдән туктаганда – туктату чоры һәм туктатылган кулланучылар исемлеге.

3.2.2. Мәгълүматларны җыю Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлегендә кәгазь һәм электрон чыганакларда оештырыла һәм Тукай муниципаль районының җылылык белән тәэмин итү схемасын эшләү өчен туплана.

3.2.3. Карар кабул итү өчен мәгълүматны анализлау һәм бирү.

Җылылык челтәрләрендә мәгълүматны анализлау һәм бирү системасы зарарланган, иң ышанычсыз челтәрләрне сайлап алу нигезендә, бирелгән финанслау күләменнән чыгып, ремонт планнарын оптимальләштерү бурычын хәл итүгә юнәлтелгән.

Мәгълүматларны статистик эшкәртү өчен төп мәгълүмат чыганагы булып ремонт чорында опрессовка нәтиҗәләре тора, алар җылылык челтәрләрен ремонтлау һәм сузуны диагностикалау һәм планлаштыруның төп ысулы буларак кулланыла.

Мониторинг мәгълүматлары объектның чын торышын ачыклау, ялган мәгълүматны төшереп калдыру һәм оптималь идарә карары кабул итү максатында, объектның актуаль паспорт характеристикаларына йөкләнә.

## 4. Мониторинг системасының эшләве

Мониторинг системасы объект һәм муниципаль дәрәҗәдә эшли.

Объект дәрәҗәсендә мониторинг системасының оештыру-методик җитәкчелеген һәм эшчәнлеген координацияләүне җылылык белән тәэмин итү объектларын эксплуатацияләүче оешмалар гамәлгә ашыра.

Муниципаль дәрәҗәдә мониторинг системасының оештыру-методик җитәкчелеген һәм эшчәнлеген координацияләүне ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар, Тукай муниципаль районының бердәм дежур-диспетчерлык хезмәте, Тукай муниципаль районының Башкарма комитеты гамәлгә ашыра.

## 5. Мониторингның төп принциплары

Мониторингның төп принциплары булып тора:

- җылылык челтәрләренең һәм җылылык белән тәэмин итү объектларының техник торышы турында мәгълүмат алуның законлылыгы;
- җылылык челтәрләренең һәм җылылык белән тәэмин итү объектларының техник торышын күзәтү өзлексезлеге;
- мониторинг нәтиҗәләреннән файдалануның ачык булуы;
- мониторинг нәтиҗәсендә алынган мәгълүматларның дөреслеге.